ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иштуган т.ю.р.б., Үзәк урам, 11 йорт
тел. (84362) 42-0-37

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИШТУГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422050, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.ж.д.р. Иштуган, ул. Центральная, 11
тел. (84362) 42-0-37

e-mail: Isht.sab@tatar.ru

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

2018 нче елның 29 нчы мае № 15

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенә кергән торак пунктларның гомуми кулланыштагы урыннарда беренчел янгын сүндерү чаралары исемлеген раслау турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан, 1994 елның 21 декабрендә кабул ителгән 69-ФЗ номерлы “Янгын куркынычсызлыгы турында” һәм 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” федераль законнар, 2004 нче елның 28 нче июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” законының 15 номерлы статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба районы Иштуган авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1.1.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге биләмәсендәге гражданнарның үз милкендә (яки кулланышында) булган биналар һәм корылмаларда булырга тиешле беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь исемлеген расларга. (кушымта итеп бирелә).

1.1.2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге биләмәсендәге торак пунктларның гомуми файдалануда кулланышта булган урыннарда булырга тиешле беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь исемлеген расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Милек милек төренә бәйсез рәвештә оешма һәм учреждение җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

2.1. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан расланган исемлек нигезендә беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь белән тәэмин итәргә.

2.2. Беренчел янгын сүндерү чараларын һәм янгынга каршы инвентарьны урнаштырган щитны бина һәм корылмаларның тышкы ягына урнаштырыга.

2.3. Беренчел янгын сүндерү чараларын һәм янгынга каршы инвентарын һәркем ала алырлык булуын тәэмин итәргә, беренчел янгын сүндерү чараларын, аларның паспорт мәгълүмәте нигезендә төзек хәлдә тотарга, тиешле сертификатлары булмаганда куллануга юл куймаска, һәм янгынга каршы инвентарьны һәм янгынга каршы инвентарьны тиешле булмаган очракта кулланмаска.

2.4. Беренчел янгын сүндерү чараларын һәм янгынга каршы инвентарьны сатып алу, ремонтлау, саклау һәм кулланышка әзер торуына җаваплы затны билгеләргә.

3. Үз милкендә (яки кулланылышта) булган бина元лары һәм корылмалары булган гражданнарга:

3.1. Расланган нигезләмә нигезендә беренчел янгын сүндерү чараларын һәм янгынга каршы көрәш инвентарьларын булдырырга.

3.2. Беренчел янгын сүндерү чараларын җитештерүче завод җитәкчелегенең эксплуатацияләү нигезендә карап тотарга.

Иштуган авыл җирлеге башлыгы: Р. Ш. Галиахметов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 нче елның
29 маенда кабул ителгән
15 номерлы карары белән
РАСЛАНДЫ

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге территориясендәге милектәге (яки кулланылыштагы) биналары һәм корылмалары булган гражданнарга, биналарда һәм корылмаларда булырга тиешле беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь исемлеге**

| № п/п | Биналар һәм корылмалар-ның атамасы | Сакланучы мәйдан | Янгын сүндерү һәм янгынга каршы инвентарь (штук) | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Порошоклы утсүндергеч (ОП-4 яки шуңа охшаш) | 0,5 куб. м сыйдырышлы ком белән ящик | Бочка белән су һәм чиләк | Багор, балта, көрәк |
| 1 | Дачалар һәм даими яшәү өчен биналар | Бина | 1(*) | | 1(*) | 1,1,1 (*) |
| 2 | Даими яшәү өсен шәхси йортлар | Бина | 1 | | 1(*) | 1,1,1 |
| 3 | Шәхси гаражлар | Гараж | 1 | “ | - | “ |
| 4 | Күп фатирлы торак йортлар | Фатир | 1 | | “ | “ |

Искәрмә:

1. ( * ) яшәү чоры белән билгеләнә (җәйге вакыт)
2. Коридор тибындагы торак йортларда һәр катка кимендә ике утсүндергеч билгеләнә.
3. Коридорларда урнаштырылган ут сүндерү чаралары кешеләрне куркынычсыз эвакуацияләүдә комачауламаска тиеш, аларны күренә торган урыннарында бинадан чыгу юлында 1,5 м биеклектә урнаштырырга кирәк.
4. Утсүндергечләр һәрчак карап торырга, алар һәрчак төзек хәлдә һәм тутыртылган булырга тиеш.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Иштуган авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 нче елның
29 маенда кабул ителгән
15 номерлы карары белән
РАСЛАНДЫ

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге территориясендәге торак пунктларның, гомуми файдаланудa кулланышта булган урыннарны беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарьләре белән җиһазландыруны тәэмин итүне тәкъдим иткән исемлек**

| № п/п | Механикалаштырылмаган корал һәм инвентарь, беренчел янгын сүндерү чаралары атамасы, | Янгынга каршы щитның комплектация нормалары |
|---|---|---|
| 1 | Утсүндергечләр (рекомендуемые):<br>- 10 л сыйдырышлы һавалы-күбекле (ОВП),<br>- порошоклы (ОП)<br>Сыешлы, кг | 2 |
| | - ОГТ-Ю/9 | 1 |
| | - ОП-5/4 | 2 |
| 2 | Лом | 1 |
| 3 | Чиләк | 1 |
| 4 | Багор | 1 |
| 5 | Асбестлы полотно, тупас йон тукыма яки войлок (кошма, янмый торган материалдан тукыма) кимендә 1х1 м үлчәмле | 1 |
| 6 | Штыклы көрәк | 1 |